РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ ИШТУГАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422050, Республика Татарстан, Сабинский район, п.ж.д.р. Иштуган, ул. Центральная, 11
тел. (84362) 42-0-37

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИШТУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы, Саба районы, Иштуган т.ю.р.б., Үзәк урам, 11 йорт
тел. (84362) 42-0-37

e-mail: Isht.sab@tatar.ru


**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

30.04.2021г. №10

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Советының 05.07.2019 елда №18 карары белан расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге территориясендә гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидәрә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезенда, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге территориясендә гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» 05.07.2019 елда №18 карары белан расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге территориясендә гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 17.1 пунктының 2 абзацына тубәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә: «яки муниципаль берәмлек халкын.»;

1.2. 5.7. пунктны тубәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Гражданнар арасында сораштыру билгеләү турында карар җирлек Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү өчен «Интернет» мәгълүмәт-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайты файдаланылырга мөмкин. Авыл җирлеге Советының гражданнарның сораштыру билгеләү турында норматив хокукый актында билгеләнә:

1. сораштыру үткәрү датасы һәм сроклары;
2. сораштырулар үткәргәндә тәкъдим ителә торган (тәкъдим ителә торган) сораштыру (сораштырулар) формулировкасы;
3. сораштыру үткәрү методикасы;
4. сораштыру кәгазе формасы;

5. сораштыруда катнашучы муниципаль берәмлек халкының минималь саны;
6. «Интернет» мәгълүмәт-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтыннан файдаланып, гражданнар арасында сораштыру уздырган очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе.»

Иштуган авыл җирлеге башлыгы Д.М.Гайнутдинов